«Ватанны сөю - иманның бер өлешедер»

# Сәлам
## (МИР)

6 +

Самар өлкәсе татарларының милли-мәдәни һәм рухи-мәгърифәтчелек гәҗитәсе
Национально-культурная и духовно-просветительская газета татар Самарской области

№ 5 (94), 17 июнь 2013 ел (8 Шәгъбән 1434 ел)

## Патриотическое воспитание мусульманской молодежи

В Уфе состоялось совещание полномочного представителя президента Российской Федерации в ПФО Михаила Бабича с руководством духовных управлений мусульман округа. Основной целью разговора стала разработка стратегии совместной работы органов власти и духовенства для решения проблем, связанных с активизацией экстремистских движений.

— Нас беспокоит, что продолжают действовать сторонники экстремистских объединений. В некоторых регионах они пытаются проводить публичные акции в свою поддержку, прикрываются лозунгами защиты прав человека. Мы должны не только с точки зрения органов власти, но и духовного сообщества, иметь принципиальную позицию и начать открыто об этом говорить, — подчеркнул Михаил Бабич.

По мнению полпреда президента РФ, проблема экстремизма имеет связь с вопросом миграции из стран с преобладанием мусульманского населения.

**Так, в 2012 году на миграционный учет в ПФО было поставлено более миллиона человек, из них 75 процентов прибыли из стран Средней Азии и Закавказья.**

Для предотвращения распространения их идеологии в нашей стране, по словам Михаила Бабича, духовным управлениям мусульман необходимо принимать активное участие в адаптации мигрантов к жизни в России.

Еще одна проблема связана с недостатком подготовленных кадров среди имамов.

Как сообщил полпред, **на территории ПФО действует 21 медресе, но они лишь частично загружены.** Поэтому существует необходимость создания программы духовно-патриотического воспитания мусульманской молодежи. Для решения этих вопросов следует, по словам Михаила Бабича, создать институт кураторства по конкретным проблемам среди духовных управлений мусульман округа.

— **Проблемой сегодня является отсутствие стабильности в мусульманской умме. Наблюдается соперничество, нездоровая конкуренция, отсутствие объединительных начал. Все это ведет к разобщению и используется радикалами. Поэтому необходимо создать условия для согласия между мусульманскими лидерами,** – сказал полпред.

Также Михаил Бабич отметил, что за последние годы хаотичный характер приобрело зарубежное образование. Если по линии духовных управлений мусульман в субъектах ПФО направлено за границу обучаться около 300 человек, то самостоятельно уехали 5000 студентов. Таким образом, большая часть граждан остается вне поля зрения, и может быть носителями нетрадиционных религиозных взглядов.

***Али СУЛЕЙМАНОВ.***

**Яңа төзелеш**

## *Хворостянкада мәчет төзелә*



**Нигез ташын салуда Вагыйз хәзрәт Яруллин катнашты**

Илебездә барган кискен үзгәрешләр иреклекләр белән бергә төрле кыенлыклар һәм билгесезлек тә тудырдылар. Кеше табигате шундый ки, тормыш җиңеләйсә, байлык килсә - ул ызгышып-талашып, алдашып-урлашып аны үстерергә, күбәйтергә тырыша. Ә бәла-каза, авырлыклар килсә, алга тулы билгесезлек, өметсезлек басса - ул Аллаһы Тәгаләне искә төшерә, ярдәм сорый.

Дин - ул кешеләр күңелендә тирән хисләр уята, бөек көчкә, Аллаһы Тәгалә кодрәтенә таяну теләге тудыра. Билгеле, һәр халык бу юлны үзенчә сайлый.

Хворостянка районында яшәгән мөселманнарда мәчет булдыру теләге элгәреддән яшәп килде. Ниһаять, аңа нигез салынды. Мәчет бинасын кора башлауга багышланган митингта Самар өлкәсе Диния нәзарәте исеменнән Вагыйз хәзрәт Яруллин, Газизҗан Сафиуллин, Хворостянка районы администрациясе башлыгы Виктор Махов, аның урынбасары Александр Адаевский, мәхәллә рәисе Фәрид Рахмаев, Йосыф Еникеев һәм Ринат Курмашаев катнаштылар.

Мәчет төзү - ул авыр, җаваплы һәм изге эш. Биредә җирле халыкның рухи халәте, күңел байлыгы сынала. Кайда гына мәчет салынмасын, аларны төзүдә танылган эшмәкәрләребез ярдәм күрсәтәләр. Хворостянка мәчетенең нигезен коруда да милләттәшләребез үз өлешләрен керткәннәр.

Алар:

Әнвәр Бульхин. Ул кирпеч, кабель бирде һәм акчалата зур ярдәм итте.

Гамәл Замалетдинов. Агач материаллары бирде.

Хәмит Әюпов. Фундамент блоклары китерде.

Али Сөләйманов, Али Әюпов. Акчалата зур ярдәм күрсәттеләр. Бу шәхесләрнең төрле төбәкләрдә мәчетләр төзүгә һәрвакыт ярдәм итүләрен дә искә төшерү урынлы булыр.

Хворостянкада яшәүче Хәмзә Котов һәм Рәисә Әхмәрова да төзелешкә зур өлеш керттеләр.

Башка диннәрне тоткан шәхесләрнең дә бу изге эшкә кулларыннан килгәнчә ярдәм итүләре дә матур күренеш. Мәсәлән, Хворостянка районы администрациясе башлыгы Виктор Махов төрле яклап ярдәм итә. Моның өстенә ул әле үзе исеменнән дә акчалата зур ярдәм иткән. Шулай ук Николай Булохов, Сергей Исаков, Алексей Дубашин, Владимир Гураев һәм Ару үз өлешләрен керттеләр.

Мәчет бинасының беренче кирпечләрен куйганда Вагыйз хәзрәт Яруллин һәм Хворостянка районы администрациясе башлыгы Виктор Махов сөйләгәннәрдән кайбер фикерләр.

Вагыйз хәзрәт Яруллин:

“Мәчетләр гомер-гомергә халыкны тәрбияләү, берләштерү һәм дин юлына тарта торган үзәкләр булып хезмәт иттеләр. Хәзерге үзгәрешләр чорында халык бигрәк тә дингә мохтаҗ. Кешеләр тәртипле, дус булып яшәсәләр, тормыш мул һәм бәрәкәтле булачак. Менә хәзер бу мәчетнең бинасы төзелә башлады. Ул - булачак Аллаһы Тәгалә йорты. Аның кодрәте ярдәмендә мәчет, һичшиксез, төзелеп бетәчәк. Ул гасырлар буена дин учагы һәм халыкны дингә чакыручы үзәк булып хезмәт итәчәк”.

“Бу мәчет үзара дус яшәргә өндәүче изге урын булачак. Рәсәйдә, Самар өлкәсендәге кебек, Хворостянка районында да төрле халык яши. Безнең эшебезнең, тормышыбызның иминлеге, уңышлылыгы - аларның дус яшәүләренә, бер-берсен хөрмәт итә белүләренә бәйләнгән. Ә мондый төпле тәрбияне бары тик дин генә бирә ала. Шуның өчен киләчәктә бу мәчет тә тагын бер тәрбия мәркәзе булыр, дип өмет итәбез”, - диде Хворостянка районы администрациясе башлыгы Виктор Махов.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**

## *Милли тормыш һәм дин*

Казан шәһәрендә IV Бөтенроссия татар дин әһелләренең “Милли тормыш һәм дин” исемле форумы булып узды. Анда 650гә якын делегат катнашты. Алар Рәсәйдәге Балтыйк диңгезеннән алып Ерак Көнчыгышка кадәр сузылган төрле җирләрдән килделәр.

Бу форумда югары дәрәҗәле дәүләт, дин һәм җәмгыять оешмалары җитәкчеләре һәм галимнәр катнаштылар.

Татарстан җитәкчеләре, югары дәрәҗәле дин эшлеклеләре һәм төрле җирләрдән килгән кунаклар трибунадан үзләренең уй-фикерләрен сөйләп, теләкләрен белдерделәр. Алар арасында Самар мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллин да бар иде.

Бу форумда чыгыш ясаучыларны тыңлагач, аларның тәкъдимнәрен исәпкә алып, резолюция кабул ителде.

Бу форумда куелган сораулар хәл итүне көтәләр. Биредә күп кенә акыллы фикерләр, изге теләкләр әйтелде. Ләкин алар күбесенчә декларатив рәвештә сөйләнделәр. Күп проблемалар әлегә сөйләнү рәвешеннән узып, тормышка ашу дәрәҗәсенә барып җитә алмыйлар. Югары дәрәҗәле дин башлыклары арасында тулы аңлашучанлык, бердәмлек булмавы да безне, гади мөселманнарны, борчый.

Әлбәттә, Татарстан хөкүмәте, татар җәмәгатьчелеге тарафыннан искиткеч зур эшләр алып барыла.

Әле күптән түгел “Диндә милләт юк. Диннең дә, милләтнең дә - һәркайсысының үз юлы”, - дигән надан сөйләшүләр артта калды. Бүгенге көндә татар милләте Ислам дине язмышын, ә дин әһәлләре татар халкының язмышын, киләчәген кайгыртып, милләтебез дәрәҗәсен, әхлакый үзаңын үстерү, рухын баету өчен тырышалар.

Ләкин алда дин әһелләренең белемен үстерү, булачак имамнарны заман таләпләренә туры китереп әзерләү һәм дини лидерлар арасында үзара аңлашучанлык, бердәмлек булдыру өчен нык тырышасы бар.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**